СОВЕТ
НОВОКИШИТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Новая, д. 1А, с. Новый Кишит,
Арский муниципальный район, 422034

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КИШЕТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Яңа урам, 1А йорты, Яңа Кишет авылы,
Арча муниципаль районы, 422034

Тел. (84366)55-4-42, факс (84366)55-4-42. E-mail: Nvk.Ars@tatar.ru

**Яңа Кишет авыл җирлеге Советы карары**

**«04» июнь 2024 ел** **№ 99**

**Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүне өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңа Кишет авыл җирлеге » муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Яңа Кишет авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2024 елның 1 гыйнварына аерым салым түләүчеләргә караган, түләү һәм (яки) түләтү түбәндәге нигезләр буенча мөмкин булмаган җирле салым суммалары өлешендәге бурычларны түләтүне өметсез дип танырга:

1) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта, үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бурычлар булу;

2) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча оешмаларга яки шәхси эшмәкәрләргә исәпләнгән бурычлар булу;

3) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң, физик затларның мөлкәтенә салым буенча 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу;

4) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң, физик затларның җир салымы буенча 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу.

2. Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүне өметсез дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслый торган документлар:

1) әлеге карарның 1 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

а) физик затның яшәү урыны буенча салым органыннан бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) үлем белән бәйле рәвештә салым органнарында физик затны исәптән төшерү турында мәгълүмат;

в) мирас хокукы турында таныклык бирү буенча мәгълүмат булмау турында салым органы белешмәсе;

2) әлеге карарның 1 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

а) оешманың, шәхси эшмәкәрнең, шәхси эшмәкәр статусын югалткан физик затның исәпкә алу урыны буенча салым органыннан бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) салым гамәлдән чыгарылган норматив хокукый акт (исеме, датасы, номеры) турында мәгълүмат;

3) әлеге карарның 1 пунктының 3 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда, салым органыннан 500 сумнан артмаган бурыч булу турында белешмә;

4) әлеге карарның 1 пунктының 4 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда, салым органыннан 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу турында белешмә.

3. «Җирле салымнар суммасы буенча бурычларны түләтүне өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» Яңа Кишет авыл җирлеге Советының 2023 елның 18 нче маендагы 80 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында «Җирлекләр» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Яңа Кишет авыл җирлеге » муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Яңа Кишет авыл
җирлеге башлыгы — Ф.И.Ахмадуллин